ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2021 Казан ш. № 218-35/кс-2021

«Идел-Кама су урман транспорты фәнни-тикшеренү һәм конструктор-технологик институты эксперименталь-җитештерү заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2022 елга агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Идел-Кама су урман транспорты фәнни-тикшеренү һәм конструктор-технологик институты эксперименталь-җитештерү заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ЭПЗ ВКНИИВОЛТ» ҖЧҖ) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп, агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ЭПЗ ВКНИИВОЛТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп,

ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2021 № 218-35/кс-2021
карарына кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ЭПЗ ВКНИИВОЛТ» ҖЧҖ өчен 2022 елга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| | Казан шәһәре | | |
| 1 | «ЭПЗ ВКНИИВОЛТ» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 8,13 | 8,13 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге